ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.04.2024**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1122**

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2024 елның икенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 888 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында, Яшь гаиләләргә торак алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2024 елның икенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясенең нормативын 86 071 (сиксән алты мең җитмеш бер) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.С.Бауэр